ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.07.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1892**

Зеленодольск муниципаль районында торак программалары (социаль наемнан тыш) буенча исәпкә куйганда һәм гражданнарга торак биргәндә торак мәйданы нормалары турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50 статьясын , Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районында дәүләт торак программалары (социаль наемнан тыш) буенча торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алганда, исәп нормасын торак урынының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына торак урынының гомуми мәйданы 18 кв. метрдан да ким булмаган күләмдә билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районында дәүләт торак программалары (социаль наемнан тыш) буенча торак биргәндә, гаиләнең бер әгъзасына 18 кв. метр күләмендә гомуми торак урыны мәйданы, ләкин ялгыз яшәүче граждан өчен 33 кв. метрдан да ким булмаган гомуми торак урыны мәйданы һәм ике кешедән торган гаилә өчен 42 кв. метрдан да ким булмаган торак урыны мәйданы күләмендә торак урын бирү нормасын билгеләргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А.Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев